КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 29 июль г.Казань № 629

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 6 июль, 494 нче, 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле

үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә теркәлгән 2 нче кушымтага, түбәндәге эчтәлекле 21 – 24 нче пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| «21. | Ярлылык дәрәҗәсен киметү, процент | Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты | ел саен | статистика мәгълүматлары |
| 22. | Хисап чоры өчен sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгын файдаланып милеккә сатылган яки арендага бирелгән муниципаль мөлкәт өлеше, процент | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен | V = A / B × 100,<br>монда:<br>A – хисап чоры өчен Татарстан Республикасының муниципаль районы (шәһәр округы) милкендә булган, sale.zakazrf.ru электрон сәүдә мәйданчыгында урнаштыру юлы белән милеккә сатылган яки арендага бирелгән мөлкәт объектлары саны, берәмлек;<br>B – Татарстан Республикасының муниципаль районы (шәһәр округы) милкендә булган, милеккә сатылган яки арендага бирелгән мөлкәт объектларының гомуми саны, берәмлек.<br>Хисап чоры – агымдагы елның кварталы (1 гыйнвардан 31 мартка кадәр, 1 апрельдән 30 июньгә кадәр, 1 июльдән 30 сентябрьгә кадәр, 1 октябрьдән 31 декабрьгә кадәр шул ук эзлеклелектә). Хисап чорының соңгы көне ял көненә туры килгән очракта, хисап чорының ахыры итеп хисап кварталындагы соңгы айның соңгы эш көне санала |
| 23. | Хисап елы башына җир кишәрлекләрен түләүсез алу өчен исәпкә баскан күпбалалы гаиләләрнең гомуми санында җир кишәрлекләрен түләүсез алган күпбалалы гаиләләр өлеше, процент | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен (арта бара торган йомгак белән) | V = A / B × 100,<br>монда:<br>A – хисап көненә җир кишәрлекләрен түләүсез алган күпбалалы гаиләләр саны, гаиләләр саны;<br>B – хисап елы башына җир кишәрлекләрен түләүсез алу өчен исәпкә алган күпбалалы гаиләләрнең гомуми саны, гаиләләр саны; |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | Хисап көне – хисап кварталындагы соңгы айның соңгы көне (31 март, 30 июнь, 30 сентябрь, 31 декабрь шул ук эзлеклелектә). Билгеләнгән хисап көне ял көненә туры килгән очракта, хисап көне итеп хисап кварталындагы соңгы айның соңгы эш көне санала |
| 24. | Муниципаль милек хокукы танылган таләп ителми торган җир өлешләре мәйданы өлеше, процент | Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы | квартал саен (арта бара торган йомгак белән) | $V = A / B \times 100$,<br>монда:<br>А – муниципаль милек хокукын тану турында суд карары булган таләп ителми торган җир өлешләре мәйданы, гектар;<br>В – Татарстан Республикасының муниципаль районы территориясендә таләп ителми торган җир өлешләренең гомуми мәйданы, гектар.<br>Хисап көне – хисап кварталындагы соңгы айның соңгы көне (31 март, 30 июнь, 30 сентябрь, 31 декабрь шул ук эзлеклелектә). Билгеләнгән хисап көне ял көненә туры килгән очракта, хисап көне итеп хисап кварталындагы соңгы айның соңгы эш көне санала». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин